Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

15 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 129 номерлы Татар Казысы авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татар Казысы авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

Гражданнар җыенын дүрт этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп, Яңа урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кооператив, Яшьләр урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамы йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабын 2021 елның 29 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Комсомол, Ерак урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Татар Казысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татар Казысы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Кәримуллин